РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**СОВЕТ**
**Большекляринского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Олы Кариле**
**авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

ул. Советская, 9,с. Большие Кляри, 422837
тел. (84377)32-2-42, факс: (84377) 32-2-42
ОКПО 04308901 ОГРН 1031638400364
ИНН/КПП 1622001763/162201001

Совет урамы, 9,Олы Кариле авылы, 422837,
тел. (84377)32-2-42, факс: (84377) 32-2-42
ОКПО 04308901 ОГРН 1031638400364
ИНН/КПП 1622001763/162201001

**3 декабрь 2019 ел** **№6**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлегенең Олы Кариле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә **карар бирәм**:

***1.*** 2019 елның 13 декабрендә 10 сәгать 00 минутка, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлегенең Олы Кариле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын билгеләргә.

***2.*** 2019 елның 14 декабрендә 10 сәгать 00 минутка, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлегенең Олы Кариле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2 этабын билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге территориясе, Чаллы авылында яшәү урыны буенча

теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

* Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

* Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру;

* Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау эшчәнлеген оештыру;

* Халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру;

* Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын оештыру;

« ӘЙЕ»　　　　　　　　　　　«ЮК».

4.Гражданнар җыенын үткәрү өчен авыл җирлегендә яшәүчеләрнең исемлеген бүлү тәртибе:

а) беренче этапта эш (хезмәт) графигы кемгә мөмкинлек бирә, кем эш көннәрендә катнаша ала, шул яшәүчеләр катнашалар.

б) икенче этапта эш (хезмәт) графигы эш көннәрендә катнашырга мөмкинлек бирмәгән яки шәхси (гаилә) шартлары аркасында катнаша алмаганнар катнаша ала.

5. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә (бастырып чыгарырга):

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Олы Кариле авылы, Пионер урамы, 1;

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Чаллы авылы, Ленин урамы, 43;

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Кече Кариле авылы, Вахитов урамы, 16, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 10 көн эчендә урнаштырырга.

6. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Олы Кариле авыл җирлеге**
**башлыгы　　　　　　　　　　Ф.Г. Гарифуллин**